СОВЕТ НИЖНЕШАНДЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1, с. Зюри,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422153

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШҮЛӘҢГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 1 нче йорт, Җөри авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422153

тел.(факс): (85563) 3-87-31; e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение                                                  Карар

“18” ноября 2016 г.                                      № 2-15

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы № 1-6 карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 29.09.2016 елның 29 сентябрендәге 72-ТРЗ, 2016 елның 21 апрелендәге 22-ТРЗ номерлы, 2016 елның 6 июлендәге “Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законының 8 һәм 32 статьяларына һәм “Мниципаль хезмәт турында” Татарстан Республикасы кодексының 29 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” № 51-ТРЗ Татарстан Республикасы законнары, “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы № 1-6 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.2. 3.6. статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә, шулай ук яллаучы (эш бирүче) вәкиленең тиешле карары булганда - белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә.

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре муниципаль хокукый актлар белән әлеге статьяның 3 абзацында билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен типовой квалификация таләпләре нигезендә билгеләнә. Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә квалификация

таләпләре муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә карап аның вазыйфаи Инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясендә шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен югары белем булу; вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яки урта һөнәри белем булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә ике ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә биш ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы.

Өлкән һәм кече төркемнәрнең муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификация таләпләре билгеләнми.

Әлеге статья максатларында муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрнең дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт вазыйфаларында һәм башка төр федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында эш стажы исәпкә алына.

1.3. Контракт буенча билгеләнеп куела торган муниципаль районның (шәһәр округының) җирле администрациясе башлыгы вазыйфасына кандидатларга өстәмә таләп белән кимендә биш ел идарә эшчәнлеге тәҗрибәсе булуы билгеләнә. Идарә эшчәнлеге дигәндә әлеге өлештә оешма, дәүләт органы, Муниципаль орган җитәкчесе, җитәкчесе урынбасары вазыйфаларында, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларында эшләү аңлашыла. Контракт буенча билгеләнеп куела торган җирле администрация башлыгы вазыйфасына кандидатларга өстәмә таләпләр шулай ук муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнергә мөмкин».

1.4. 5 статьяның 5.10 пунктчасында беренче абзацны төшереп калдырырга.

1.5. 7 статьяның 7.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктчасы өстәргә::

"9.1)әлеге Нигезләмәнең 11.1 статьясында каралган белешмәләрне тапшырмау.»

1.6. Түбәндәге эчтәлектәге 11.1 статья өстәргә:

«11.1 Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштыру турында белешмәләр тапшыру.

11.1.1 муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткәр һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматларны урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге битләре турында белешмәләрне яллаучы вәкиленә тапшыралар:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан-муниципаль хезмәткә керү елына кадәрге өч календарь ел өчен хезмәткә кергәндә;

2) муниципаль хезмәткәр-күрсәтелгән мәгълүматны тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен, муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын үтәү кысаларында һәркемгә ачык мәгълүмат урнаштыру очракларыннан тыш, ел саен.

11.1.2. Әлеге статьяның 11.1.1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан муниципаль хезмәткә кергәндә, ә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла. Әлеге статьяның 11.1.1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән форма буенча тапшырыла.

11.1.3. Яллаучы вәкиле карары буенча ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан урнаштырылган һәркемгә ачык мәгълүматны эшкәртәләр, шулай ук әлеге статьяның 11.1.1 өлешендә каралган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерәләр.

1.5  12.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктчасы өстәргә:

«10.1) әлеге Нигезләмәнең 11.1 статьясында каралган белешмәләр;».

1.6 15 статьяның 15.2 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә, шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләре-яллаучы (эш бирүче) вәкиленең муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасын биләү өчен белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләренә туры килү таләп ителүе турындагы карары булганда;».

1.7 6 статьяның 6.5 пунктының 12 пунктчасында " үзенең турыдан-туры башлыгының» сүзләрен «яллаучының (эш бирүченең) вәкиленең»сүзләренә алмаштырырга.

1.8  8 статьяның 8.1 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) вазыйфаи хәлгә яисә вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата бүләкләү, ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачулар, ял, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләүләр) алырга.

Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр тарафыннан алынган бүләкләр муниципаль милек дип танылa һәм муниципаль хезмәткәр тарафыннан ул муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органына, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә акт буенча тапшырыла, моңа Россия Федерациясе Граждан кодексында билгеләнгән очраклар керми. Беркетмә чарасына, хезмәт командировкасына яисә башка рәсми чарага бәйле рәвештә

алган бүләген тапшырган муниципаль хезмәткәр аны Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;»

1.9 9 статьяның 9.1 һәм 9.2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.1 Әлеге Нигезләмә максатларында "коррупциягә каршы көрәш турында" Федераль законның 10 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән "мәнфәгатьләр конфликты" төшенчәсе кулланыла.";

9.2 Әлеге Нигезләмә максатларында "коррупциягә каршы көрәш турында" Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән "шәхси кызыксыну"төшенчәсе кулланыла.

1.10 9 статьяның 9.4 пунктында «акцияләр белән " һәм «акцияләр» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.11 18 статьяның 18.4 пунктында «Татарстан Республикасы законнары һәм Уставы» сүзләрен «Уставы»сүзенә алмаштырырга.

3 2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Башлыгы Е.М.Михайловага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башлыгы,
Сове рәисе

Е.М.Михайлова